# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү тәртибе турында” 2005 елның  20 июлендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 7 – 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“куллану кәрзине – кеше сәламәтлеген саклау һәм аның тормыш эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле азык-төлек продуктларының, шулай ук азык-төлек булмаган товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең минималь җыелмасы, аларның хакы азык-төлек продуктларының минималь җыелмасы хакына нисбәттә билгеләнә;”;

2) 2 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацында “чыгымнарга куллану бәяләре дәрәҗәсе” сүзләреннән соң “һәм азык-төлек продуктларына куллану бәяләре индекслары” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

“Татарстан Республикасында минималь куллану бюджеты турында” 2008 елның 23 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 7 (I өлеш), 2 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“2. Яшәү минимумы – куллану кәрзине хакын бәяләү, шулай ук мәҗбүри түләүләр һәм җыемнар.”.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2013 елның 13 июле
№ 61-ТРЗ